Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

2018 елның 30 ноябре №14

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге гражданнарының үзарасалым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексын, «Россия Федерациясендә җирлеүзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законын, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын, 2018 елның 18 ноябрендәге җирле референдумда кабул ителгән карарын, Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2018 елның 20 ноябрендәге 50 номерлы территориаль сайлау комиссиясе карарын гамәлгә ашыру максатларында, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авылҗирлеге башкарма комитеты карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге гражданнарының узара салым акчасын җыюның тәкъдим ителегән Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Питрәч районы, Чыты авылы, Совет ур., 126а йорт (АҖ бинасы фасады), Иске Йорт авылы, Кооператив ур., 64 йорт (АК бинасы фасады)адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Чыты авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе С.Ә. Фәйзрахманов

Кушымта 1
Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында
2018 елның 30 ноябре № 14

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге гражданнарының үзарасалым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. 1 төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучылар, БөекВатан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларнын тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы булган студентлардан, 90 яшькә җиткән гражданнардан тыш,18 яше тулган, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар, аларның җирле референдумда катнашу, катнашмавына һәм мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә 2019 елның 01 апреленә кадәр үзара салым түләүне тормышка ашырырга тиеш.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (белдерү) бланкы Чыты авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында гражданнар игътибарына (www.pravo.tatarstan.ru)һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайты (www.pestreci.tatarstan.ru), һәм почта элемтәсе аша да, кулга тапшыру юлы белән җиткерелә.

Хәбәрнамәдә (белдерүдә) гражданнарның үзара салым акчаларын күчерү реквизитлары, бер тапкыр түләү суммасы тулы күләмдә, аны түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлегенең шәхси счетына керә

5. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (сылтама буенча) почта күчерү юлы белән башкарыла https://uslugi.tatarstan.ru/.

6. Түләү фактын раслау булып касса ордерыквитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

Кушымта 2
Татарстан Республикасы Питрәч
муниципаль районы Чыты авыл
җирлеге башкарма комитеты
карарына үзгәрешләр кертү хакында
2018 елның 30 ноябре № 14

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Чыты авыл җирлеге
бюджетына үзарасалым кертү буенча бер тапкыр түләү турында
БЕЛДЕРМӘ (УВЕДОМЛЕНИЕ) № _____

Түләүченең Ф. И. атасының
исеме________________________________________________________________________
_____
Адрес: ___________________________________________________________
_______________________________________________________________нигезендә
Сезгә, түбәндәгереквизитларбуенча:________________ срогынакадәр, __________
суммада, чараларнытормышкаашыруөченбертапкыртүләүтүләргәкирәк
Алучы Банк БИК _____________________________________
Сч. № _________________________________
Алучы Сч. № ________________________________________
ИНН ________________________________________
КПП ________________________________________
КБК ______________ ОКАТО _________________
Түләүбилгеләү________________________________________________________________
____________

Җитәкче _________________ ________________________________________
М.П. (имза) (имза расшифровкасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү өчен - - - - - - - - - - - - - - -

600 (алты йөз) сум күләмендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Чыты авыл җирлеге бюджетына үзара салым кертү буенча бер тапкыр түләү
турында белдермә (уведомление) № _____

Түләүченең Ф. И. атасының исеме________________________________________
Адрес:
__________________________________________________________________________
Алды «__» _______________ 20__ ел. ______________________________________
(түләүче имзасы)
*Искәрмә. Корешокның өзелгән өлеше Чыты авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.*